ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

28.02.2023

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

д. им. М. Вахитова

Вахитов авыл җирлегендә 2023нче елның язгы чорында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында.

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары, Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә, уңайсыз табигый-климат шартлары барлыкка килү чорында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының конструктив элементларының сыйдырышлыгын киметүне булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 1 апреленнән 30 апрелена кадәр Вахитов авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап 6 тоннадан артык авырлыктагы йөк белән яки йөксез транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә (алга таба - язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү) .
2. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү "Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү" 3.12 юл билгеләрен урнаштыру юлы белән, Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган "Транспорт чаралары арбасы тибы" өстәмә мәгълүмат билгеләре (табличкалар) 8.20.1 һәм 8.20.2 билгеләре белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
3. Россия Эчке эшләр Министрлыгының “Югары Ослан” муниципальара бүлеге ЮХИДИ бүлеген Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне тикшереп торуны оештырырга тәкъдим итәргә.
4. 2022 елның 1 апрелена кадәр җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында вакытлыча чикләүләр кертү турында мәгълүмат урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Каримов